ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 гыйнвар 2021 ел № 264

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен муниципаль бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартын билгеләү тәртибе турында» 2011 елның 17 мартындагы 1244 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С. Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 20 гыйнварындагы
264 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе

1. бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен муниципаль бюджет һәм автономияле учреждениеләргә (алга таба – Учреждение) субсидия (алга таба – Субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидия, Субсидия бирү максатын һәм, Субсидия тиешле проектны (программаны) тормышка ашыру максатларында бирелгән очракта, илкүләм проект (муниципаль программа), шул исәптән, тиешле илкүләм проект (программа) составына керә торган федераль проект, яки федераль проект максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проект исемен күрсәтеп, Башкарма комитет карарына туры китереп төзелгән Субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә, «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан бирелә.

2 бүлек. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3. Субсидия алу өчен Учреждение Башкарма комитетның тармак органына җибәрә:

1) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча Субсидия алуга заявка;

2) Субсидия суммасының исәп-хисап - нигезе;

3) бюджет акчаларын бирү кирәклеге нигезләрен, шул исәптән тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, мөлкәт (күчемсез мөлкәттән тыш) сатып алуга беренчел сметаны, шулай ук тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик мәгълүматларны һәм (яки) башка мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуы;

4) Субсидия бирү максаты булып ремонт (реставрация) үткәрү торса, ремонтланырга тиешле объектлар исемлеге, мондый объектларны тикшерү акты һәм дефект ведомосте, чыгымнарның беренчел сметасы;

5) Субсидия бирү максаты булып мөлкәт сатып алу торган очракта, сатып алырга планлаштырыла торган мөлкәт турында мәгълүмат;

6) Субсидия бирү максаты булып чаралар үткәрү торса, чаралар программасы һәм аларны үткәрүгә чыгымнар сметасы;

7) Субсидия бирү максаты булып күрсәтелгән түләүләрне гамәлгә ашыру торган очракта, түләүләрне алучы физик затлар саны һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат.

4. Учреждение чараны үткәрү тәртибен күздә тоткан муниципаль хокукый актта күрсәтелгән датага яки Субсидия бирү турында шартнамә төзү планлаштырыла торган айдан соң килә торган айның 1 числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы, шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән Субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары булмау, Учреждениене үзгәртеп оештыру яки ликвидацияләү буенча чараларны гамәлгә ашыруга, авария (гадәттән тыш) хәлләрен булдырмау, авария (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта, тискәре нәтиҗәләрне бетерү һәм торгызу эшләрен гамәлгә ашыруга, закон көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны түләүгә Субсидия бирү очракларыннан, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, Башкарма комитет карарлары белән билгеләнгән башка очраклардан тыш;

2) үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы башка юридик затның юридик затка кушылу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), ликвидацияләнү процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, учреждение эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булу.

5. Субсидия күләме, шәһәр бюджетында тиешле максатларга каралган акчалар чикләрендә, һәр Учреждениегә карата Башкарма комитетның финанс идарәсе белән килештереп, Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан билгеләнә.

6. Башкарма комитетның тармак органы өч эш көне эчендә әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган документларны карап тикшерә һәм Субсидия бирүдән баш тарту турында карар яисә, Субсидия күләмен нигезләүче мәгълүматны күрсәтеп (аларны исәпләү формуласы һәм куллану тәртибе һәм (яки) Субсидия бирү максатларыннан чыгып, башка мәгълүмат), Субсидия күләме һәм (яки) аны исәпләү тәртибе күрсәтелгән һәм чара үткәрү тәртибен күздә тоткан Башкарма комитет карары проектын әзерли.

7. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

1) Учреждение тарафыннан тапшырылган документлар әлеге тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү (аларны билгеләгәндә) яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган күләмдә тапшыру);

2) Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

3) тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларының кирәкле күләме булмау.

8. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, учреждение әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган документларны кабат Башкарма комитетка тапшырырга хокуклы.

9. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган Башкарма комитет карары нигезендә финанс идарәсе, әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча, Субсидия бирү турында шартнамә проектын әзерли.

10. Субсидия агымдагы финанс елына шәһәр бюджетында әлеге максатларга каралган күләмдә бирелә. Субсидия күләме чаралар программасы, чыгымнар исемлеге һәм (яки) чыгымнар сметасы нигезендә билгеләнә.

11. Субсидия, үз эченә түбәндәгеләрне алган Субсидия бирү турында шартнамә нигезендә бирелә:

1) Субсидияләр тиешле проектны (программаны) тормышка ашыру максатларында бирелгән очракта, илкүләм проект (муниципаль программа), шул исәптән, тиешле илкүләм проект (программа) составына керә торган федераль проект, яки федераль проект максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проект исемен күрсәтеп, Субсидия бирү максатлары турында;

2) конкрет һәм үлчәнә торган булырга һәм федераль яки региональ проектлар (программалар) нәтиҗәләренә туры килергә тиешле Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре (әгәр Субсидия мондый проектны тормышка ашыру максатларында бирелсә) һәм, тиешле проектлар нәтиҗәләренә ирешкәндә алырга планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яки) хезмәтләр өлешендә күрсәткечләрнең зурлыкларын да кертеп, Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында (мондый детализация мөмкинлеге булганда);

3) Субсидия күләме;

4) Субсидия күчерү сроклары (графигы);

5) хисап бирү сроклары.

6) Учреждение тарафыннан Субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән Субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, Субсидия суммасын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

7) Субсидия бирү турында шартнамәгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегән очракта;

8) күрсәтелгән шартнамәгә, аңа үзгәрешләр кертү яки аны өзү мөмкинлеген күздә тота торган өстәмә килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе. Шартнамә өзелгән очракта, күрсәтергә кирәк:

- Башкарма комитет карары буенча аны берьяклы тәртиптә, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп оештыру яки ликвидацияләү; Учреждение тарафыннан хокукый акт һәм (яки) шартнамәдә билгеләнгән Субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылу сәбәпле, аны срогыннан алда туктату өчен нигезләрне;

- Учреждение тарафыннан берьяклы тәртиптә шартнамәне өзү тыелуны.

12. Башкарма комитетның финанс идарәсе Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Яр Чаллы шәһәре буенча территориаль бүлекчәсенә (алга таба – казначылык органы) тапшыра:

1) Субсидия бирү турында төзелгән шартнамәне;

2) әлеге тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча, чираттагы финанс елына Субсидияләр исемлеге;

3) һәр максатчан Субсидия буенча Субсидия кодлары киселешендә Субсидияләр керү суммасының агымдагы финанс елына планлаштырыла торган бюджет классификациясе кодларын күрсәтеп, Учреждениеләрнең акча йөкләмәләрен түләүне гамәлгә ашыру өчен, агымдагы елда әлеге тәртипкә 4 нче кушымтада каралган форма буенча тапшырылган Субсидияләр белән операцияләр турында мәгълүматлар.

## 3 бүлек. Хисаплылыкка таләпләр һәм Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

13. Учреңдение, хисап елыннан соң килүче елның 31 декабренә кадәр срокта, Субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында Башкарма комитетның тармак органына хисап тапшыра.

14. Башкарма комитет Субсидия бирү турындагы шартнамәдә Учреждение тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

15. Башкарма комитет исеменнән Башкарма комитетның тармак органы һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе, Субсидия алучы тарафыннан Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшырылган көннән башлап 10 эш көне эчендә, Субсидия алучының Субсидия бирү шартларын, максатларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

16. Башкарма комитет тарафыннан Субсидия бирү, бирелгән Субсидиядән файдалану шартлары, максатлары һәм тәртибе, бозылу һәм (яки) Субсидия бирү турында шартнамәдә каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, өч эш көне эчендә

Учреждениегә кимчелек турында белдерү кәгазе һәм Субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрелә.

Учреждение, кимчелек турында белдерү кәгазен һәм Субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә, Субсидияне кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

17. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында бюджет йөкләмәләре белән расланмаган Субсидия калдыгы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көнендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елы – Субсидия алучы әлеге Тәртиптә каралган документларны Башкарма комитет адресына җибәргән ел.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесе

______________________________

Шәһәр бюджетыннан Субсидия бирү турында
заявка

_____________________________________________________________________________
(гариза бирүченең исеме)

_________________________________________________________________ максатында

_______________________ (________________________________________) күләмдә,
(сүзләр белән)

____________________________________________________________________ счетына

шәһәр бюджетыннан Субсидия бирү мөмкинлеген карауны сорый.

Кушымта: теркәлә торган документлар исемлеге.

Вәкаләтле затның
вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы

М.У.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә муниципаль бюджет яисә автономияле учреждениегә шәһәр бюджетыннан Субсидия бирү турында шартнамә

Яр Чаллы шәһәре «___» _____________ 20__.

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе исеменнән, алга таба «Гамәлгә куючы» дип атала, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе ________________________________________, бер яктан, һәм __________________________________ исеменнән, алга таба «Учреждение» дип атала, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче ________________________________________, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр

## I. Шартнамәнең предметы

1.1. Әлеге Шартнамәнең предметы булып, Башкарма комитетның ________________________ елның ______ номерлы карары нигезендә, _____________________________ өчен 202__ елда Учреждениегә шәһәр бюджетыннан ________ сум ____ тиен күләмендә Субсидия ( алга таба – Субсидия) бирү тора.

1.2. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре: _________________________________

## II. Субсидия бирү шартлары һәм күчерү тәртибе

2.1. Субсидия 31.12.20_____ кадәр срокта, ТР ФМ КД Яр Чаллы шәһәре буенча территориаль бүлекчәсендә Учреждениегә ачылган Учреждениенең аерым шәхси счетына күчерелә.

## III. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Гамәлгә куючы бурычлы:

1) Учреждениегә Субсидияне Шартнамәдә билгеләнгән срокларда күчерүне гамәлгә ашырырга;

2) Учреждение тарафыннан әлеге Шартнамә шартлары үтәлешен, шулай ук Субсидиянең максатчан файдаланылуын, шул исәптән тикшерүләр үткәрү юлы белән контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

3) Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

3.2. Гамәлгә куючы хокуклы:

1) Учреждениедән әлеге Шартнамәне үтәү өчен кирәкле документларны һәм материалларны соратып алырга;

2) түбәндәге очракларда әлеге Шартнамәгә үзгәрешләр кертү юлы белән Субсидия күләмен үзгәртергә:

- тормышка ашыру өчен Субсидия бирелә торган максатларга (чараларга, эшләр составына) тиешле төзәтмәләр кертүне исәпкә алып, бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыру яисә киметү турында карар кабул иткәндә;

- Учреждение тарафыннан нигезле заявка бирелү шарты белән, тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда, Учреждениенең өстәмә чыгымнарны гамәлгә ашырудагы ихтыяҗын анализлау;

- әгәр Учреждение тарафыннан Субсидия бирү максатларына ирешүне тәэмин итү чыгымнары әлеге Шартнамәдә каралган күләмнән кимрәк булса, шулай ук Гамәлгә куючы тарафыннан Учреждениенең нигезсез Субсидия калдыклары булу турында карар кабул ителсә, кирәк булган очракта Субсидия күләмен күрсәтелгән калдыклар суммасына киметергә;

- норматив хокукый актларга үзгәрешләр, шул исәптән Субсидия бирү буенча чыгым йөкләмәләрен билгели торган башка максатлар өчен Субсидияләр бирү мәсьәләләрен җайга сала торган үзгәрешләр кертергә;

3) аларны шул ук максатларга юнәлдерүгә ихтыяҗ булганда, чираттагы финанс елында Учреждениегә Субсидия калдыкларын кире кайтару турында карар кабул итәргә;

4) Учреждение тарафыннан Субсидиядән файдалану турында хисап бирү сроклары бозылган очракта, Субсидия бирүне туктатырга;

5) Гамәлгә куючы, шулай ук муниципаль финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрнең йомгаклары буенча, әлеге Шартнамәдә билгеләнгән максатлар һәм шартлар бозылу фактлары ачыкланган очракта, билгеләнгән тәртиптә Субсидия бирүне туктатырга;

6) Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

3.3. Учреждение бурычлы:

1) әлеге Шартнамәдә билгеләнгән Субсидия бирү шартлары нигезендә, Субсидияне максатчан билгеләнеше буенча файдаланырга, шул исәптән,:

- Гамәлгә куючының запросы буенча, әлеге Шартнамәдә күрсәтелгән Субсидия бирү шартлары үтәлешен тикшерү өчен кирәкле документларны, аның тарафыннан билгеләнгән срокларда тапшырырга;

- мондый үзгәрешләр зарурлыгы ачыкланганнан соң, Гамәлгә куючыга Субсидиядән файдалануның Субсидия күләмен үзгәртүгә йогынты ясарга мөмкин булган шартларын үзгәртү кирәклеге турында хәбәр итәргә;

- Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Субсидиядән файдалану турында хисапны __________________ соңга калмыйча Гамәлгә куючыга тапшырырга;

- чираттагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган Субсидия калдыкларын билгеләнгән тәртиптә кире кайтарырга;

- Гамәлгә куючы, муниципаль финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрнең йомгаклары буенча, әлеге Шартнамәдә билгеләнгән Субсидия максатларын һәм шартларын бозулар ачыкланган очракта, Субсидиянең файдаланылган суммаларын кире кайтаруны гамәлгә ашырырга;

- Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән срок эчендә Субсидиядән файдалану буенча фактик чыгымнар тулы күләмдә башкарылмаган булса, шулай ук Гамәлгә куючы тарафыннан Учреждениенең нигезсез Субсидия калдыклары булу турында карар кабул ителгән очракта, Гамәлгә куючы карары буенча Субсидияне яки аның өлешен күрсәтелгән калдыклар суммасына кире кайтарырга;

2) Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Шартнамәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

3.4. Учреждение хокуклы:

1) чыгымнарның финанс-икътисадый нигезләрен күрсәтеп, Субсидия күләмнәрен үзгәртү зарурлыгы ачыкланган очракта, әлеге Шартнамәгә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим белән Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итәргә;

2) әлеге Шартнамәнең үтәлешенә бәйле аңлатмалар буенча Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итәргә;

3) Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Шартнамәдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## IV. Якларның җаваплылыгы

4.1. Әлеге Шартнамә буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Яклар арасында әлеге Шартнамә үтәлешенә бәйле килеп чыга торган бәхәсләр, мөмкин кадәр, тиешле беркетмә яки башка документлар рәсмиләштереп, сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителә. Яклар арасында килешүгә ирешмәгән очракта, бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Шартнамәгә өстәмә килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________.

5.3. Әлеге шартнамәне берьяклы тәртиптә срогыннан алда туктату өчен нигезләр:

учреждениене үзгәртеп оештыру яки ликвидацияләү;

Учреждениенең хокукый акт һәм (яки) шартнамә белән билгеләнгән Субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылу.

5.4. Шартнамә Яклар тарафыннан имзаланган датадан башлап үз көченә керә, ләкин әлеге Шартнамәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәнгә кадәр түгел, һәм 20___ елның «31» декабренә кадәр гамәлдә була.

5.5. Әлеге Шартнамәне үзгәртү, әлеге Шартнамәгә аның аерылгысыз өлеше булып торган өстәмә килешү формасында язма рәвештә Яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла, һәм Яклар тарафыннан имзаланганнан соң үз көченә керә.

5.6. Әлеге Шартнамәне өзү Якларның үзара ризалыгы буенча гына мөмкин.

5.7. Әлеге Шартнамә язма рәвештә, һәр Як өчен берешәр итеп, ике нөсхәдә төзелгән.

## VI. Якларның түләү реквизитлары

## VII. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | Директор |
| _______________ | _______________ |
| М.У. | М.У. |

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә муниципаль бюджет яисә автономияле учреждениегә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамәгә кушымта

Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында
хисап

| № т/б | Субсидия алучының исеме | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең исеме | Шартнамә төзү датасына нәтиҗәлелек күрсәткеченең зурлыгы | Хисап датасына нәтиҗәлелекнең фактик күрсәткече | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Кушымта: раслый торган документларның күчермәләре.

Вәкаләтле затның вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы

Башкаручы ________________ ____________ ______________________
(имза) (вазыйфа) (имзаның расшифровкасы)

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

____________________________________________________________

(гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган исеме )

Башкарма комитет Җитәкчесе

_______________ ____________________________

(имза)

20_____ елга
муниципаль учреждениегә бирелгән
максатчан субсидияләр исемлеге

| | | КОДЛАР |
|---|---|---|
| | | |
| | Шәхси счет № | |
| | | |
| | ИНН | |
| Учреждение | КПП | |
| | | |
| | БК буенча бүлек | |
| Эш йөртүче функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органының исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | |
| | | |
| | | |
| | | |
| Бюджетның исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | |
| | Элекке мәгълүматларны бирү датасы | |

Учреждениенең шәхси счетын алып баруны гамәлгә ашыра торган органның исеме ТР ФМ КД Яр Чаллы шәһәре ТБ

Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| № т/б | Максатчан субсидияләр исемлеге | Сумма | Субсидияләр бирелүгә нигез булып торган норматив документның исеме |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |

Директор ____________ Ф. И. А.и.
(имза)

Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы ________
(имза)

Баш
бухгалтер
________________ Ф.И.А.и.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 4 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

(гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган исеме )

Башкарма комитет
Җитәкчесе

______________ (имза)

______________ (имзаның расшифровкасы)

20_____ елга
муниципаль учреждениегә бирелгән
субсидияләр белән операцияләр турында мәгълүматлар

| | КОДЛАР |
|---|---|
| | |
| Шәхси счет № | |
| | |
| ИНН | |
| КПП | |
| БК буенча бүлек | |
| Элекке мәгълүматларны бирү датасы | |
| | |

Учреждение

Эш йөртүче функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органының исеме — Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

Бюджет исеме — Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты

Учреждениенең шәхси счетын алып баруны гамәлгә ашыра торган органның исеме — ТР ФМ КД Яр Чаллы шәһәре ТБ

Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| Субсидияләрнең исеме | Субсидияләрнең коды | Бюджет классификациясе коды | Керемнәр | | Планлаштырыла торган түләүләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел башына акчаларның файдалану өчен рөхсәт ителгән калдыгы | Планлаштырыла торган керемнәр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Директор ____________ (имза) Ф.И.А.и.

Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы ____________ (имза)

Баш бухгалтер ____________ Ф.И.А.и.